| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

15.01.2024 Казан ш. № 13-р

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Салым салу максатларында биналардан (корылмалар, каралтылар) һәм бүлмәләрдән фактик файдалану төрен билгеләү турында” 28.11.2023 № 3355-р Карарына үзгәреш кертү турында

“Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясына, “Оешмалар милкенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге № 49-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының $1^1$ статьясына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 23.12.2016 № 977 карары белән расланган Салым салу максатларыннан биналарның (корылмаларның, каралтыларның) һәм бүлмәләрнең фактик файдалану төрен билгеләү тәртибенә һәм Салым салу максатларыннан биналарның (корылмаларның, каралтыларның) һәм бүлмәләрнең фактик файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карау буенча комиссия турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3.101 пунктына таянып, һәм Салым салу максатларында биналардан (корылмаларның, каралтыларның) һәм бүлмәләрдән фактик файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карау буенча комиссиянең 09.01.2024 № 1 карары нигезендә:

1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Салым салу максатларында биналардан (корылмалар, каралтылар) һәм бүлмәләрдән фактик файдалану төрен билгеләү турында” 28.11.2023 № 3355-р Карарының кушымтасына 57 нче пунктны төшереп калдырып үзгәреш кертергә.

2. Карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының www.mzio.tatarstan.ru адресындагы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көнендә үз көченә керә

4. Әлеге карарны контрольдә тотуны Татарстан Республикасының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**